
# ЧИШМӘ БАШЫ

№6, Апрель, 2025

МБГБУ «Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе”








**ЭКОЯЗ** | **12 АПРЕЛЬ – КОСМОНАВТИКА КӨНЕ** | **ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 139 ЕЛ**

**БУ САНДА:**


- 1 Апрель – Халыкара Кошлар көне.
- Санитар икеайлык – “ЭКОяз – 2025”
- 12 апрель – Космонавтика көне
- 22 апрель – Халыкара Җир – Ана көне
- 26 апрель – Габдулла Тукайның туууына 139 ел


## АПРЕЛЬ АЕНДА ИСТӘЛЕКЛЕ ДАТАЛАР




### 1 апрель - Халыкара кошлар көне.

Бу көн гүзәл табигатебезгә һәм канатлы дусларыбызга хөрмәт тәрбияләү көне буларак билгеләп үтелә, чөнки нәкъ менә шушы вакытта канатлы кошлар туган якларына карата бөек мәхәббәт хисләрен уяталар. Яз көне бөтен табигать җанлана, яңадан туа. Кояш яктырак һәм җылырак карый башлый, битләрне йомшак җил иркәли, өлгереп җитмәгән җирләр өлгерә, агачларның бөреләре ачыла. Күчмә кошлар туган якларына әйләнеп кайталар.

Кыр казлары һәм кыр үрдәкләре туган якка яз килүен хәбәр итеп, мең километрлап юл үтәләр.

**1 апрельдән Татарстанда традицион санитар-экологик икеайлык башланды.**



Мәктәп укучылары һәм укытучылар “Җиргә бакча бүләк ит” акциясендә катнашып, мәктәп ишек алдында агач үсентеләре утырттылар.



Алан башлангыч мәктәбендә укучылар белән тирә-якны чистарту эшләре алып барылды.



Сарай-Чокырча авылы башлангыч мәктәбендә мәктәп территориясе чүп-чардан чистартылды, коры-сары җыештырылды, тиешле тәртипкә китерелде.

## 12 апрель – космонавтика көне



**1961 елның 12 апреле – дөнья күләмендә тарихка кереп калган истәлекле дата.**

**Бу көнне космоска кешелек тарихында беренче пилотлы очыш ясалды. Галәмгә беренче мәртәбә юл ачкан тарихи вакыйганы һәм легендар Юрий Гагаринны искә алмаган кеше юктыр.**










**Космонавтика көнен бәйрәм итү кысаларында Алан башлангыч мәктәбендә "Космик кроссвордны ачыкла» уены узды. Уен ни өчен бу көн космонавтика көне дип саналуы турындагы әңгәмәдән башланды. Аннары укучылар конкурсларда бик теләп катнаштылар. Алар космос, күк җисемнәре һәм космонавтлар турындагы белемнәрен күрсәттеләр.**

## Бөтенроссия "Эколятлар көне"




**Ел саен үткәрелә торган Бөтенроссия "Эколятлар көне" кысаларында 1 нче сыйныф укучылары өчен "Эколятлар- яшь табигать сакчылары"дигән тематик дәрес үткәрелде. Укучылар экологик проблемалар, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, әкият геройлары - Эколятлар белән таныштылар. Балалар эколятларның табигатьне саклау буенча бары тик яхшы һәм дөрес гамәлләр генә эшләвен белделәр.**

# ТУКАЙ ЯШИ, ТУКАЙ – МӘҢГЕЛЕК!


26 апрель – татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көне Татарстанда күркәм традициягә әверелеп, Туган тел көне буларак билгеләп үтелә. Югары шигъриятнең какшамас күперләре белән төрле мәдәни традицияләрне бергә кушып, шагыйрь Россиягә һәм бөтен дөньяга татар рухының байлыгын күрсәтте, төрле милләт һәм дин вәкилләрен тынычлыкка, дустанә яшәүгә һәм хезмәттәшлеккә өндәде. Кыска, ләкин иҗади казанышларга бик бай тормыш кичереп, ул татар әдәбиятында гына түгел, халык күңелендә дә җуелмаслык эз калдырды. Горурланып һәм хөрмәтләп, аны “безнең Тукай” дип атый алабыз.

Бу көн - татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көнендә мәктәптә оештырылган Тукай айлыгына нәтиҗәләр ясау көне дә. Тукай айлыгы кысаларында оештырылган чараларның максаты – татар теленә, Габдулла Тукай әсәрләрен өйрәнүгә кызыксыну тудыру, туган телгә ихтирамлы караш тәрбияләү ул.

Габдулла Тукайның тууына 139 ел тулу уңаеннан мәктәптә төрле чаралар уздырылды, укучыларыбыз тарафыннан Г.Тукай әсәрләренең геройлары төрле яклап чагылдырылды. Тукай шигырьләрен сәнгатьле укучылар конкурсы, әсәрләре буенча төрле иллюстрацияләр, Г.Тукайның тормышы һәм иҗатына багышланган видеофильмнар карау, әдипнең тормышы һәм иҗаты буенча интеллектуаль уеннар, викторина сораулары, сәхнәләштерелгән эпизодлар - моның ачык мисалы булып тора.

Бу айда үткәрелгән бәйгеләр, конкурслар Г. Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын төрле яклап тирәнтен өйрәнергә ярдәм итте. Укучылар әлеге чараларда актив катнаштылар, куанычлы нәтиҗәләр күрсәттеләр. Тукайның тормышы, иҗаты, аның геройлары бүген дә халкыбыз тарихында иң якты, иң изге сәхифәләрнең берсе булып тора.

**Садриева Н.З. татар теле һәм әдәбияты укытучысы, китапханәче**




***26 АПРЕЛЬ-ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК ШАГЫЙРЕ ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 139 ЕЛ (1886-1913)***

**2025 елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреатлары билгеле. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тиешле указны имзалады.**

**Лауреатлар булып 3 мәдәният эшлеклесе һәм авторлык коллективы танылды.**

**Шагыйрь Рәниф Шәриповка «Җомга» һәм «Бөртек-бөртек яктылык» китаплары өчен;**

**Драматург Мансур Гыйләҗевка – «Бичура», «Баскетболист», «Игезәкләр» һәм башка пьесаларны үз эченә алган «Мәхәббәт сүзлеге» пьесалар җыентыгы өчен;**

**Фотограф һәм фотожурналист Рифкать Якуповка – Татарстан фото сәнгатен үстергән һәм иҗатында татар халкының рухи һәм мәдәни тормышын чагылдырган, аның мәдәни мирасын саклауга керткән зур өлеше һәм «Сабантуй» фотоальбомы өчен;**

**Айрат Кашаев, Александр Полубенцев һәм Илнур Гайфуллин составындагы авторлар коллективы – «Иакинф» балетын куйган өчен.**





**Мәктәбебездә "Тукай яши, Тукай мәңгелек!" дип исемләнгән кичә үткәрелде. "Су анасы" һәм "Кызыклы шәкерт" командалары Тукай иҗаты буенча белемнәрен сынадылар. Командалар җаваплар әзерләгән арада укучыларыбыз сәнгатьле итеп Г.Тукай шигырьләрен укыдылар, сәхнәләштерделәр, җырларын башкардылар.**

**Бөек шагыйребезнең туган көненә багышланган кичә татар халкының гимнына әверелгән “Туган тел” җырын башкару белән тәмамланды.**

**Бу дөньяда бик аз яшәп, үзеннән соң бай мирас калдырган язучыларны искә төшергәндә, беренче чиратта, Габдулла Тукай күз алдына килә. Ул бары тик 27 ел гына яшәп кала. Шушы вакыт эчендә бик күп шигырьләр яза, үзеннән соң бай мирас калдыра.**

**Г. Тукай- татар шигъриятенең иң якты йолдызы, милли горурлыгы.**

**Мәктәбебездә Г.Тукайның тууына 139 ел тулуга багышланган "Милләтемнең җырчы тургае" дигән китап күргәзмәсе эшли башлады. Анда Тукайның тормышы һәм иҗат юлы турында китаплар, шагыйрьнең балалар өчен язылган шигырьләре, Тукай турында кызыклы фактлар белән танышырга мөмкин.**

# 22 АПРЕЛЬ — ХАЛЫКАРА ҖИР-АНА КӨНЕ.



**Барлык илләрдә дә 22 апрельдә Җир көнен билгеләп үтәләр. Бу - чиста Су, Җир һәм Һава бәйрәме. Бу көнне Җир йөзендә булган экологик һәлакәтләр турында искә төшереп, шушы экологик проблемаларны чишүдә нинди өлеш кертә алуыбыз турында уйланырга тиешбез.**

**Бүген мәктәбебездә «Туган җиребезне саклыйк!» дигән темага ачык мероприятие булды. Бу кичәдә башлангыч сыйныф укучылары, Татарстан Республикасының биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты "Ашыт" дәүләт табигый тыюлыгы белгечләре Әхмәтҗанов Рәшит Зиннур улы һәм Абдрахманова Гөлнара Ильяс кызы катнашты. Кунакларыбыз укучылар каршында туган илебездәге экологик проблемалар турында сөйләделәр. Соңыннан укучылар белән бергә агачлар утыртылды.**









## Ял сәгатьләрендә




**Сәхифәне *әзерләделәр*:** башлангыч сыйныф укытучылары Шәрәпова З.М., Хәбибуллина Н.Р.

**Редакция һәм нәшриятның адресы:** 422024, Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 11нче йорт
**E- mail:** Sskor.Ars@tatar.ru

**Социаль челтәр бите:** https://vk.com/77arsk_srkorsa